**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 августындагы 2933 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 461 номерлы карары белән расланган «ПГУ – 250 мәйданчыгыннан читтә урнашкан инженерлык челтәрләре һәм корылмалары» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аларның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карары нигезендә карар бирәм:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 461

номерлы карары белән расланган «ПГУ – 250 мәйданчыгыннан читтә урнашкан инженерлык челтәрләре һәм корылмалары» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 10 сентябрендәге 2290 номерлы, 2025 елның 24 сентябрендәге 3147 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), ызанлау проектының аерым өлешләрен әлеге карарның кушымтасы нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, ясала торган җир кишәрлегенең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 19 августындагы
2933 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 25 февралендәге 461 номерлы карары белән расланган «ПГУ – 250 мәйданчыгыннан читтә урнашкан инженерлык челтәрләре һәм корылмалары» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. «Ясала торган җир кишәрлекләре турында мәгълүматлар булган нигезләмә» дигән III бүлектә:

1.1. ясала торган җир кишәрлекләре исемлегендә:

1.1.1. «Төзелеш-монтаж эшләре чорына җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү» таблицасында:

1.1.1.1. 47 нче юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| **№ т/б** | **Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше** | **Ясала торган җир кишәрлегенең контурын билгеләү** | **Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегенең категориясе** | **Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Җир кишәрлеген (өлешен) ясау ысулы** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «47 | 16:50:310203:347/чзу2 | — | 478 | Торак пунктлар җирләре | Күпфатирлы йортларның инженерлык инфраструктурасы объектлары | Җир кишәрлегенең бер өлешен (сервитут) ясау» |

1.1.1.2. түбәндәге эчтәлектәге 52 нче юл өстәргә:

| **№ т/б** | **Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше** | **Ясала торган җир кишәрлегенең контурын билгеләү** | **Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегенең категориясе** | **Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Җир кишәрлеген (өлешен) ясау ысулы** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «52 | 16:50:310301:731/чзу3 | — | 299 | Торак пунктлар җирләре | Күпфатирлы йортларның инженерлык инфраструктурасы объектлары | Җир кишәрлегенең бер өлешен (сервитут) ясау» |

1.1.2. «Файдалану чорына җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү» таблицасында:

1.1.2.1. 46 нчы юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| № т/б | Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше | Ясала торган җир кишәрлегенең контурын билгеләү | Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегенең категориясе | Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре | Җир кишәрлеген (өлешен) ясау ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «46 | 16:50:310203:347/чзу2 | — | 478 | Торак пунктлар җирләре | Күпфатирлы йортларның инженерлык инфраструктурасы объектлары | Җир кишәрлегенең бер өлешен (сервитут) ясау» |

1.1.2.2. түбәндәге эчтәлектәге 50 нче юл өстәргә:

| № т/б | Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше | Ясала торган җир кишәрлегенең контурын билгеләү | Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегенең категориясе | Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре | Җир кишәрлеген (өлешен) ясау ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «50 | 16:50:310301:731/чзу3 | — | 299 | Торак пунктлар җирләре | Күпфатирлы йортларның инженерлык инфраструктурасы объектлары | Җир кишәрлегенең бер өлешен (сервитут) ясау» |

1.2. ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегендә:

1.2.1. «Төзелеш-монтаж эшләре чорына ясала торган җир кишәрлекләре» таблицасында:

1.2.1.1. «16:50:310203:347/чзу2(1)» кадастр номерын «16:50:310203:347/чзу2» кадастр номеры белән алыштырырга;

1.2.1.2. «16:50:310203:347/чзу2(2)» кадастр номерын «16:50:310301:731/чзу3» кадастр номеры белән алыштырырга;

1.2.1.3. ясала торган 16:50:310204:130/чзу2 җир кишәрлеге координатларын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә;

1.2.2. «Файдалану чорына ясала торган җир кишәрлекләре» таблицасында:

1.2.2.1. «16:50:310203:347/чзу2(1)» сүзләрен «16:50:310203:347/чзу2» сүзләре белән алыштырырга;

1.2.2.2. «16:50:310203:347/чзу2(2)» сүзләрен «16:50:310301:731/чзу3» сүзләре белән алыштырырга.

2. «Территорияне ызанлау сызымы» дигән IV бүлектә:

2.1. территорияне ызанлау сызымы фрагментын (2 нче бит) әлеге үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә;

2.2. территорияне ызанлау сызымы фрагментын (6 нчы бит) әлеге үзгәрешләрнең 3 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә;

2.3. территорияне ызанлау сызымы фрагментын (7 нче бит) әлеге үзгәрешләрнең 4 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә;

___________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 25 февралендәге 461 номерлы карары
белән расланган «ПГУ – 250 мәйданчыгыннан
читтә урнашкан инженерлык челтәрләре һәм
корылмалары» линия объекты территориясен
планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә
торган үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта

**Территорияне ызанлау сызымы фрагменты**

2 бит



Шартлы билгеләр

| | |
|---|---|
| 46 | ясала торган җир кишәрлеге/ясала торган җир кишәрлекләре өлешләре чикләренең характерлы ноктасы |
| | төзелеш-монтаж эшләре чорына ясала торган җир кишәрлекләренең, җир кишәрлекләре өлешләренең чикләре |
| | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры белешмәләре буенча гамәлдәге җир кишәрлекләренең чикләре |
| 16:50:000000:25582/ чзу1(1) | төзелеш-монтаж эшләре чорына ясала торган җир кишәрлегенең/ясала торган җир кишәрлеге өлешенең шартлы номеры |
| 16:50:000000:25582 | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры белешмәләре буенча җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | территорияне ызанлау проекты чиге |

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 25 февралендәге
461 номерлы карары белән расланган
«ПГУ – 250 мәйданчыгыннан читтә
урнашкан инженерлык челтәрләре һәм
корылмалары» линия объекты
территориясен планлаштыру һәм
ызанлау проектына кертелә торган
үзгәрешләргә 3 номерлы кушымта

## Территорияне ызанлау сызымы фрагменты

6 бит




Шартлы билгеләр

| | |
|---|---|
| 46 | ясала торган җир кишәрлеге/ясала торган җир кишәрлекләре өлешләре чикләренең характерлы ноктасы |
| | төзелеш-монтаж эшләре чорына ясала торган җир кишәрлекләренең, җир кишәрлекләре өлешләренең чикләре |
| | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры белешмәләре буенча гамәлдәге җир кишәрлекләренең чикләре |
| 16:50:000000:25582/чзу1(1) | төзелеш-монтаж эшләре чорына ясала торган җир кишәрлегенең/ясала торган җир кишәрлеге өлешенең шартлы номеры |
| 16:50:000000:25582 | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры белешмәләре буенча җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | территорияне ызанлау проекты чиге |

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 25 февралендәге 461 номерлы
карары белән расланган «ПГУ – 250
мәйданчыгыннан читтә урнашкан инженерлык
челтәрләре һәм корылмалары» линия объекты
территориясен планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
4 номерлы кушымта

## Территорияне ызанлау сызымы фрагменты

7 бит






Схема расположения листов




Шартлы билгеләр

| | |
|---|---|
| 46 | ясала торган җир кишәрлеге/ясала торган җир кишәрлекләре өлешләре чикләренең характерлы ноктасы |
| | төзелеш-монтаж эшләре чорына ясала торган җир кишәрлекләренең, җир кишәрлекләре өлешләренең чикләре |
| | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры белешмәләре буенча гамәлдәге җир кишәрлекләренең чикләре |
| 16:50:000000:25582/ чзу1(1) | төзелеш-монтаж эшләре чорына ясала торган җир кишәрлегенең/ясала торган җир кишәрлеге өлешенең шартлы номеры |
| 16:50:000000:25582 | Бердәм дәүләт күчемсез милек реестры белешмәләре буенча җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | территорияне ызанлау проекты чиге |

_______________